# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

11.11.2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 11 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 80 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

-Мостафин авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

-Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);

-Мостафин авылында чишмәне торгызу һәм аның территориясен төзекләндерү өчен материаллар сатып алу;

-Мостафин авылы Октябрь урамына вак таш сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 71 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 45 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: җыенда катнашкан 45 кеше «ЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районынын Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 250 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районынын Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы территориясендә I төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлек студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

-Мостафин авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

-Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);
-Мостафин авылында чишмәне торгызу һәм аның территориясен төзекләндерү өчен материаллар сатып алу;
-Мостафин авылы Октябрь урамына вак таш сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Петровкский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән сон 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районынын Петровский Завод авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровкский Завод авыл җирлеге башлыгы А. Б. Хөснетдинов